ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Тел./факс: (85556) 2-57-52, e-mail: landysh.sayfullina@tatar.ru, http://muslumovo.tatarstan.ru

21.01.2020 г. № 26

**Карар**

**Мөслим муниципаль районының оешмалары, предприятиеләре һәм авыл җирлекләре арасында XXX кышкы Спартакиада уздыру турында**

Халык арасында физик культураны һәм спортны, сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау, спорт осталыгын арттыру, спорт төрләре буенча җыелма команданы туплау максатларында, муниципаль район Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Мөслим муниципаль районы оешмалары, предприятиеләре һәм авыл җирлекләре арасында, 2020 елның 01 февраленнән 07 мартына кадәр, XXX кышкы Спартакиада үткәрергә.

2. Расларга:
- авыл җирлекләре арасында XXX кышкы Спартакиада Нигезләмәсен (1 нче кушымта);
- район оешмалары һәм предприятиеләре арасында XXX кышкы Спартакиада Нигезләмәсен (2 нче кушымта).

3. Мөслим муниципаль районы предприятиеләре, оешмалары җитәкчеләренә һәм авыл җирлекләре башлыкларына тәкъдим итәргә:
- команда әзерләргә;
- командалар катнашуны оештырырга;
- ярышларга бару өчен транспорт белән тәэмин итәргә;
- команда әгъзаларының туклануын оештырырга.

4. «Финанс-бюджет палатасы» МКУга, каралган финанс ассигнованиеләре кысаларында, чараларны вакытында финанслауны гамәлгә ашырырга тәкъдим итәргә.

5. «Мөслим муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ начальнигы Р.Т. Демидовка, районның гомуми урта һәм төп белем бирү мәктәпләре директорларына:
- Ярышлар уздыру өчен спорт залларын әзерләргә;
- Ярышлар үткәрү һәм командаларның тренировкалары өчен кирәкле спорт инвентарьлары бирергә.

6. Россия Эчке эшләр министрлыгының Мөслим районы бүлеге начальнигы Р.Р. Гатауллинга ярышлар вакытында хокук тәртибен тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

7. «Мөслим үзәк район хастаханәсе» ДАССУ баш табибы Р.А Морзаһановка һәм «Спорт мәктәбе» МБУ директоры И.М. Фазлыевка, ярышлар узган вакытта медицина ярдәме күрсәтү өчен, медицина хезмәткәре билгеләргә тәкъдим итәргә.

8. Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге начальнигы И.Р. Яббаровка:

- Спартакиаданы үткәрү буенча гомуми җитәкчелекне оештырырга;
- Спорт ярышлары судьяларын оештырырга һәм тәэмин итәргә;
- Ярышларда җиңүчеләргә грамоталар һәм бүләкләр әзерләргә.

9. «Спорт мәктәбе» МБУ директоры И. М. Фазлыевка, «Спорт чаралары дирекциясе» директоры М. А. Байрхановка чаңгы трассаларын, керү юлларын, автостоянкаларны әзерләргә.

10. Территориаль үсеш бүлеге начальнигы Ф.Ф. Вәлиевка ярышларны уздыру вакытында азык-төлек продуктлары сатуны оештырырга тәкъдим итәргә.

11. «Мәдәният бүлеге» МКУ начальнигы И.Ф Салихҗановка чараларның музыкаль бизәлешен тәэмин итәргә.

12. «Татмедиа» АҖ «Мөслим-информ» филиалы директоры Р.Р. Афзаловага учреждениеләрдә, предприятиеләрдә һәм авыл җирлекләрендә Спартакиадага әзерлек барышын, ярышлар нәтиҗәләрен массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны оештырырга тәкъдим итәргә.

13. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге начальнигы И. Р. Яббаровка йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе**
**вазыйфаларын башкаручы** **И. Х. Әхмәтов**

Мөслим муниципаль районы
Башкарма комитетының
«   » _________________ 2020 ел,
_____ номерлы карарына
1 нче кушымта

**Мөслим муниципаль районында, Бөек Ватан сугышында җиңүнең 75 еллыгын һәм ТАССРның 100 еллыгын бәйрәм итү кысаларында, авыл җирлекләре арасында XXX кышкы Спартакиада үткәрү турында Нигезләмә**

**1. Максатлар һәм бурычлар.**
- халык арасында спорт төрләрен популярлаштыру;
- спорт осталыгын арттыру;
- иң көчле спортчыларны һәм командаларны ачыклау;
- сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау.

**2. Үткәрү срогы һәм урыны.**

Ярышлар **2020 елның 15 февралендә** авыл җирлекләре буенча бүленгән зоналарда үткәрелә (1.1 нче кушымта). Киңәшмә һәм җирәбә салу ярышлар көнендә һәр төр буенча аерым үткәрелә. Һәр зонадан финалга бер команда чыга.

Авыл җирлекләре арасында **финал ярышлары 2020 елның 29 февралендә** «Спорт мәктәбе» МБУда (Универсаль спорт залы) узачак. Финал ярышларының киңәшмәсе һәм жирәбәсе ярышлар көнендә һәр төр буенча аерым үткәрелә.

**Суперфинал ярышлары 2020 елның 7 мартында** гомумкоманда зачетында 1 һәм 2 урыннарны алган район оешмалары, предприятиеләре һәм авыл җирлекләре командалары арасында узачак.

**3. Ярышларны уздыру шартлары һәм катнашучыларга рөхсәт.**

**Авыл җирлекләре командасы** 18 яшькә җиткән әлеге авыл җирлеге гражданнарыннан, хезмәткәрләреннән һәм студентларыннан җыела. Командаларда катнашучылар, катнашучының паспортында күрсәтелгән бу җирлектә яшәргә яки туу урынына ия булырга, яисә шушы авыл җирлегендә төп эш урыны булырга тиеш.

Бер спортчы ярышларның барлык төрләрендә дә чыгыш ясарга хокуклы. Әгәр ярышларда ялган затлар катнашса, команда җиңелүче булып санала һәм ярышларның бу төре буенча соңгы урынны били. Оешмалар һәм предприятиеләр, авыл җирлекләре арасында XXX кышкы Спартакиадада спорт оешмалары хезмәткәрләре («Спорт мәктәбе» МБУ, «Юность» СОК, Форпост) катнаша алмый.

**Спорт төрләре буенча протестлар, ярышлар вакытында һәм (яки) ярышлар төре тәмамланганнан соң, судьялар комиссиясенә 5 минут эчендә Баш судья исеменә язма рәвештә тапшырыла.**

Ярышта катнашучыларның үзләре белән булырга тиеш:

- табиб һәм авыл җирлеге җитәкчесе тарафыннан таныкланган Гариза,
- медицина белешмәсе (бассейн өчен - финалда),
- паспорт (оригинал!),
- хезмәт кенәгәсе (яисә таныкланган күчермә).

Документларсыз спортчы ярышларда катнашмый.
Юл йөрү һәм туклану – командировкага баручы оешмалар хисабына.

**4. Ярышлар белән җитәкчелек итү.**

Ярышларны уздыру муниципаль район Башкарма комитетының Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге тарафыннан гамәлгә ашырыла.

***Ярышларны уздыру түбәндәгеләргә йөкләнә:***

**«Спорт мәктәбе» МБУ, «Спорт чаралары Дирекциясе»** - судьялар составын оештыра;

**«Мөслим РУХ» ДАССОсы һәм «Спорт мәктәбе» МБУ** – авыл җирлекләрендә беренче медицина ярдәмен күрсәтү өчен медицина персоналы бирә;

**Авыл җирлекләре Башлыклары** – командаларны XXX Кышкы Спартакиадага туплый һәм катнаша, чаңгы трассаларын әзерли;

**«Спорт чаралары Дирекциясе»**– авыл җирлекләрендә (зоналарда) кышкы Спартакиаданы ачу һәм үткәрү вакытында күңел ачу-музыкаль программасы тәкъдим итә.

**Мәгариф идарәсе** – гомуми белем бирү мәктәпләренең җиһазландырылган спорт залларын бирә;

- **мәктәп директорлары, физик культура укытучылары** ярышларда катнашалар һәм авыл җирлекләре Башлыклары белән бергә кышкы спорт спартакиадасында катнашу өчен командалар туплауны, ярышлар уздыру өчен спортзалларны, инвентарьларны, чаңгы трассасын, футбол мәйданчыгын әзерләүне оештыралар. Ярышларда катнашучы командалар өчен аерым бүлмәләр бирәләр.

**Россия Эчке эшләр министрлыгының Мөслим районындагы бүлеге** - ярышлар уза торган авыл җирлекләрендә хокук тәртибен тәэмин итә.

**«Татмедиа» АҖ «Мөслим-информ»** - массакүләм мәгълүмат чараларында ярышлар процессын һәм нәтиҗәләрен яктырта.

**5. Зоналарда ярышлар үткәрү программасы һәм тәртибе:**

***Ярышлар Олимпия системасы буенча уздырыла*.**

**15 февраль, 2020 ел -** бүленгән зоналар буенча ярышлар. (Барлык ярышлар да бер көнне үткәрелә)

9:00 сәг. – Спартакиаданы ачу: Яңа Усы, Вәрәшбаш, Р. Шуган гомуми белем бирү мәктәпләренең спорт залларында, Тойгелде зонасы – «Спорт мәктәбе» МБУ спорт залында (Универсаль спорт залы).

**Ярыш төрләре:**

- <u>милли көрәш</u> - 70 кг, 85 кг һәм 85 кг. нан артык авырлык категорияләре буенча уздырыла. «Капма-каршы»;
- <u>аркан тарту</u>: Команда составы - 5 кеше;
- <u>чаңгы ярышы</u>: Катнаш эстафета (2 хатын-кыз + 2 ир-ат, 2 км.- хатын-кызлар, 3 км. – ир-атлар);
- <u>кул көрәше</u>: ир-атлар 75 кг кадәр, 90 кг һәм 90 кг.нан артык авырлыкта, хатын-кызлар 60 кг кадәр, 75 кг. һәм 75 кг.нан артык аавырлык категориясендә;
- <u>волейбол</u> (хатын-кызлар);
- <u>волейбол</u> (ир-атлар);
- <u>шахмат</u> (1 ир-ат), шашка (1 хатын-кыз).

**29 февраль, 2020 ел - авыл җирлекләре арасында финал ярышлары. Һәр зонадан 1 команда чыга.**

9:00 сәг. – Спорт мәктәбе спорт залында финал ярышларын ачу (Универсаль спорт залы)

**СПАРТАКИАДАНЫҢ Финаль этапын АЧУ**

**Үткәрү срогы:** 29 февраль, 2020 ел.
**Үткәрү урыны:** Спорт мәктәбе (Универсаль спорт залы)

**Ярыш төрләре:**

**ВОЛЕЙБОЛ һәм БАДМИНТОН**

**Үткәрү урыны:** Спорт мәктәбе спорт залы (Универсаль спорт залы)

**ВОЛЕЙБОЛ**

Волейбол буенча ярышлар өч партиядән 25 очкога кадәр, 2 очко аерма белән үткәрелә. Ике партияне бер команда откан очракта, өченче партия үткәрелми. 3 партия уены кирәк булганда, 15 очкога кадәр дәвам итә, чик очко – 17. Җиңүче очколарның иң зур суммасы буенча билгеләнә: җиңү өчен – 2 очко, җиңелү өчен – 1 очко, килмәү өчен – 0 очко бирелә.

**БАДМИНТОН**

(Команда составы 2 хатын-кыз, 2 ир-ат)

Бадминтон буенча ярыш 3 партиядән 11 очкога кадәр, 2 очко аерма белән үткәрелә. Беренче партияне команданың беренче ракеткасы уйный, икенче партияне – икенче ракетка. Ике партияне бер команда откан очракта, өченче партия үткәрелми. Отылган партияләр тигезлеге булган очракта, 3 партия парлы разрядта уйнатыла.

## МИЛЛИ КӨРӘШ,  ШАХМАТ һәм ШАШКА

**Үткәрү урыны:** Спорт мәктәбе (Универсаль спорт залы),

- Милли көрәш - по весовым категориям: 70 кг, 85 кг һәм 85 кг. нан артык вес категорияләрендә «Капма-каршы».
- Шахмат һәм шашка (шахматка 1 ир-ат һәм шашкага 1 хатын-кыз)

Ярышның формуласы катнашучы командаларның санына карап билгеләнәчәк. Җыелган очколарның иң зур суммасы буенча җиңүче билгеләнә. Ике яки берничә команданың очколары тигез булган очракта, җиңүче FIDE кагыйдәләре буенча билгеләнә.

## БИАТЛОН һәм ӨСТӘЛ ТЕННИСЫ

### БИАТЛОН

**Үткәрү урыны:** «Кояшлы Ык» яр буе.

Катнаш эстафета (2 хатын-кыз +  2 ир-ат, 1 км.- хатын-кызлар, 1 км. – ир-атлар) – “Кояшлы Ык” яр буе. Биатлон эстафета узышының беренче катнашучылары, катнашучы командалар санына бәйле рәвештә, судья командасы буенча старт ала (бергә, яисә 30 секунд вакыт интервалы белән). Билгеле бер дистанция узганнан соң (450 метр) һәр спортчыга аягүрә басып биш мишеньга ату кирәк булачак (мишень диаметры 10 см, ату дистанциясе 10 метр). Биатлончы тидерә алмаган очракта, ялгышлар саны буенча, штраф әйләнеше үтү белән җәзалана. Аннары тагын бер әйләнешне үтеп, спортчы эстафетаны киләсе катнашучыга тапшыра. Узыш барышында спортчыларга түгәрәкләрне кисүеп чыгу, штраф түгәрәкләренә игътибар итмәү, бер-берсенә аңлы физик йогынты ясау тыела. Биатлон кагыйдәләре катнашучыларга чит мишеньгә атуны тыя. Спортчының чит мишеньга төгәл эләгүе тидермәү дип санала. Ярышның җиңүчесе булып дистанциядә иң яхшы вакыт күрсәткән команда таныла. Пневматик винтовканы (бер разрядлы) команда үзе белән алып килә.

### ӨСТӘЛ ТЕННИСЫ

Өстәл теннисы буенча ярышлар өч партиядән 11 очкога кадәр, 2 очко аерма белән үткәрелә. Беренче партияне ир – ат, икенче партияне хатын-кыз

уйный. Ике партияне бер команда откан очракта, өченче партия үткәрелми. Отылган партияләр тигезлеге булган очракта, 3 партия парлы разрядта уйнатыла.

## КУЛ КӨРӘШЕ (АРМСПОРТ)

**КУЛ КӨРӘШЕ** «Капма-каршы» - Ир-атлар 75 кг. га кадәр, 90 кг һәм 90 кг. нан артык авырлык категориясендә.
**КУЛ КӨРӘШЕ** «Капма-каршы» - Хатын-кызлар 60 кг., 75 кг. Һәм 75 кг.нан артык авырлык категориясендә.

## ЙӨЗҮ, АРКАН ТАРТУ

**Үткәрү урыны:** «Мөслим гимназиясе», «Спорт мәктәбе» спорт залы (Универсаль спорт залы).

**ЙӨЗҮ** «Мөслим гимназиясе»: Эстафета (2 ир-ат + 1 хатын-кыз; 3 х 50м) ирекле стиль белән үткәрелә.

**АРКАН ТАРТУ** «Спорт мәктәбе» спорт залы (Универсаль спорт залы).

Команда составы 5 кеше, гомуми авырлыгы 450 кг. Командалар очрашуы өч омтылыштан тора. Командаларның берсе ике омтылышта җиңү яулаган очракта, өченчесе үткәрелми. Һәр омтылыштан соң командалар урыннар белән алышына һәм ял итә (ике минуттан да артык түгел). Бутсы яки башка шиплы аяк киеме рөхсәт ителми.

## СУПЕРФИНАЛ

**Үткәрү урыны:** «Спорт мәктәбе» спорт залы (Универсаль спорт залы), ССК «Юность», «Мөслим гимназиясе»

**Үткәрү вакыты: 0**7 март, 2020 ел. 9:00 сәг.

**СУПЕРФИНАЛ**да оешмалар, предприятиеләр һәм авыл җирлекләре арасында гомумкоманда зачетында 1 һәм 2 урыннарны алган командалар катнашачак. Коллегия тарафыннан билгеләнгән барлык ярыш төрләре дә бер көнне узачак. Суперфиналда барлыгы 5 спорт төре узачак, аларның 3 төре мәҗбүри.

**Алар - волейбол (хатын-кызлар һәм ир-атлар), мини-футбол (ир-атлар), бадминтон (хатын-кызлар һәм ир-атлар). Ярышларның калган 2 төре, 2 мартта «Мизгел» яшьләр үзәгендә оешмалар, предприятиеләр һәм авыл җирлекләре арасында ике җиңүче команда вәкилләре һәм авыл җирлекләре Башлыклары катнашында, җирәбә салу буенча билгеләнә.**

**Әлеге Нигезләмә ярышларга рәсми чакыру булып тора!**

Белешмәләр өчен телефон: 2-59-48

**ГАРИЗА үрнәге**
**Мөслим муниципаль районы оешмалары, предприятиеләре һәм авыл җирлекләре арасында XXX кышкы спартакиадада катнашучы**
**_____________________________________________ командасы.**

**___________________________(спорт төре)**

Дата «___» ___________2020 ел. Мөслим

| № | Ф.И.О. (тулысынча) | Туган елы | Эш урыны | Табиб рөхсәте | Табиб имзасы |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | | | | | |

Кертелгән ________ кеше
Врач ___________

Команда вәкиле: _____________ /___________/

Учреждение начальнигы: _____________ /___________/

1.1 нче кушымта

**XXX кышкы Спартакиада кысаларында**
**Мөслим муниципаль районының авыл җирлекләрен**
**ярышлар үткәрү зоналары буенча бүлү**

| **Зона-лар №** | **№ т/б** | **Авыл җирлекләре командасы** | **Район Советы һәм Башкарма комитетыннан җаваплы затлар** | **Җаваплы судьялар** |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 1 | Тойгелде а.җ. **(зона УСЗ)** | Гарипов Ренат Гимадислам улы | **Фазлыев И.М (баш судья),** Софеев И.Ф. Хафизов А.М. Сәетгалиев И.Н. Хамматуллин Н.С. Сәетгалиев И.Н. |
| | 2 | Метрәй а.җ. | | |
| | 3 | Иске Карамалы а.җ. | | |
| | 4 | Т.Табын а.җ. | | |
| | 5 | Исәнсеф а.җ. | | |
| 2 | 1 | **Р. Шуган** а.җ. **(зона)** | Әхмәтов Илнур Хатыйп улы | **Дәүләтшин А.А. (баш судья),** Хәбибуллин Ф.Ф. Кашапов И.Р. Шакирҗанов Р.Р. Латыйпов А.З. |
| | 2 | Симәк а.җ. | | |
| | 3 | Мәлләтамак а.җ. | | |
| | 4 | Баланлы а.җ. | | |
| 3 | 1 | **Вәрәшбаш** а.җ. **(зона)** | Ильясов Рөстәм Алмаз улы | **Байрханов М.А. (баш. судья),** Мадьяров Ш.Д. Мөхәммәтҗанов Н.Н. Садретдинов Л.Р. Ханов И.Р. Хафизов И.И. |
| | 2 | Олы Чакмак а.җ. | | |
| | 3 | Михайловка а.җ. | | |
| | 4 | Керәш-Шуран а.җ. | | |
| 4 | 1 | **Яңа Усы** а.җ. **(зона)** | Әхмәтҗанов Азат Мөҗәһит улы | **Мадяров И.Р. (баш судья),** Бариев Л.Х. Казанбаев А.Р. Шәймухаметов А.Р Абдуллин Р.М. |
| | 2 | Баек а.җ. | | |
| | 3 | Әмәкәй а.җ. | | |
| | 4 | Октябрь а.җ. | | |
| | 5 | Урәзмәт а.җ. | | |

1.2 нче кушымта

**Мөслим муниципаль районы авыл җирлекләре арасында**
**XXX кышкы Спартакиада очколарын исәпләү таблицасы**

| Урын – очколар саны | Урын – очколар саны | Урын – очколар саны |
|---|---|---|
| **1 - 80** | **8-51** | **15-37** |
| 2-75 | **9-48** | **16 - 36** |
| **3-70** | 10-45 | **17-35** |
| **4-65** | **11 - 43** | **18-34** |
| **5-60** | **12-41** | **19 - 33** |
| 6-57 | 13-39 | **20-32** |
| **7-54** | **14-38** | **21 - 31** |

Мөслим муниципаль
районы Башкарма
комитетының
«    » ________________
2020 ел,
_____ номерлы карарына
2 нче кушымта

**Мөслим муниципаль районында, Бөек Ватан сугышында җиңүнең 75 еллыгын һәм ТАССРның 100 еллыгын бәйрәм итү кысаларында, оешмалар һәм предприятиеләр арасында XXX кышкы Спартакиада үткәрү турында Нигезләмә**

**1. Максатлар һәм бурычлар.**

- халык арасында спорт төрләрен популярлаштыру;
- спорт осталыгын арттыру;
- иң көчле спортчыларны һәм командаларны ачыклау;
- сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау.

**2. Үткәрү срогы һәм урыны.**

Ярышлар 2020 елның 1 февраленнән 7 мартына кадәр Мөслим авылында үткәрелә. Киңәшмә 2020 елның 22 гыйнварында 14.00 сәгатьтә муниципаль район Советының актлар залында узачак.

**3. Ярышларны уздыру шартлары һәм катнашучыларга рөхсәт.**

Мөслим районы **оешмалары**, **предприятиеләре**, **мәктәпләре командалары** әлеге оешма һәм аның филиалларында даими нигездә хезмәт шартнамәсе буенча эшләүче хезмәткәрләрдән туплана. Оешмалар һәм предприятиеләр, авыл җирлекләре арасында узучы XXX кышкы Спартакиадада спорт оешмалары хезмәткәрләре («Спорт мәктәбе» МБУ, «Юность» СОК, Форпост) катнаша алмый.

Команда әгъзалары Мөслим муниципаль районында яшәргә тиеш. Мөслим районында даими нигездә эшләүче, әмма пропискасы булмаган оешма җитәкчеләренә ярышларда катнашу рөхсәт ителә.

Бер спортчы барлык ярышларда да чикләүләрсез катнашырга хокуклы. Бер команда өчен чыгыш ясаган спортчы башка команда өчен катнашырга хокуклы түгел. Мөслим муниципаль районы оешмалары һәм предприятиеләре арасында XXX кышкы Спартакиада вакытында оешма, предприятие хезмәткәрләре үз авыл җирлеге командасында катнашырга хокуклы түгел. Команда суперфиналга чыкмаган очракта, оешма яки предприятие өчен катнашкан хезмәткәр, пропискасы, яисә паспортында әлеге җирлектә туган урыны турында билгесе булса, үзенең авыл җирлеге өчен катнаша ала.

Гомуми белем бирү мәктәпләре укучылары, Мөслим политехника техникумы студентлары, учреждениеләрдә практика үтүчеләр ярышларга

кертелми. Әгәр ярышларда ялган затлар катнашса, команда җиңелүче булып санала һәм ярышларның бу төре буенча соңгы урынны ала.

Мөслим районы Росгвардия хезмәткәрләре Россия Эчке эшләр министрлыгының Мөслим районындагы бүлеге командасы өчен чыгыш ясыйлар. Спартакиада дәвамында әлеге учреждениедә эшләми торган 1 спортчы оешма өчен чыгыш ясый ала. Спортчы:

- Мөслим муниципаль районында пропискада булырга тиеш;
- Спартакиада дәвамында оешмаларның, предприятиеләрнең һәм авыл җирлекләренең башка командалары өчен чыгыш ясый алмый;
- спортчы спортчы белән алышынмый.
- 18 яшьтән өлкәнрәк булырга тиеш.

**Спорт төрләре буенча протестлар, ярышлар вакытында һәм (яки) ярышлар төре тәмамланганнан соң, судьялар комиссиясенә 5 минут эчендә Баш судья исеменә язма рәвештә тапшырыла.**

Ярышта катнашучыларның үзләре белән булырга тиеш:

- табиб һәм учреждение җитәкчесе тарафыннан таныкланган Гариза,
- медицина белешмәсе (бассейн өчен),
- паспорт,
- Хезмәт кенәгәсе (яисә таныкланган күчермә).

Юл йөрү һәм туклану – командировкага баручы оешмалар хисабына.

Спортчыларга ярышларда бары тик ак табанлы спорт аяк киеменнән генә катнашырга рөхсәт ителә. Спартакиаданың ачылу, ябылу тантанасыда һәм ярышлар вакытында барлык катнашучылар (спортчылар һәм җанатарлар) Универсаль спорт залына алмаш аяк киемнәреннән керергә тиеш.

## 4. Ярышлар белән җитәкчелек итү.

Ярышларны уздыруның гомуми җитәкчелеге муниципаль район Башкарма комитетының Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге тарафыннан гамәлгә ашырыла.

***Ярышларны уздыру түбәндәгеләргә йөкләнә:***

**«Спорт чаралары Дирекциясе», «Спорт мәктәбе» МБУ** - судьялар составын оештыру, чаңгы трассаларын әзерләү.

**«Мөслим гимназиясе» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе** - йөзү бассейнын әзерли;

**«Мөслим РҮХ» ДАССОсы һәм «Спорт мәктәбе» МБУ** - һәр ярышка беренче медицина ярдәме күрсәтү өчен медицина персоналын бирә;

**Барлык милек формасындагы район оешмалары һәм предприятиеләре җитәкчеләренә** – XXX кышкы спартакиадага командаларны туплау һәм катнашу;

**«Спорт чаралары Дирекциясе»** – кышкы спартакиаданы ачу һәм уздыру вакытында музыка-күңел ачу программасы әзерли; җиңүчеләргә тантаналы рәвештә бүләкләр тапшыруны Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге белән берлектә оештыра;

**Мәгариф идарәсе –** гомуми белем бирү мәктәпләренең җиһазландырылган спорт залларын бирә;

– мәктәп директорлары, физик культура укытучылары ярышларда катнашалар һәм кышкы спартакиадада катнашу өчен командалар туплауны оештыралар. Спорт заллары, хоккей тартмалары, тренировкалар һәм ярышлар үткәрү өчен чаңгы трассалары әзерлиләр.

**«Татмедиа» АҖ «Мөслим-информ» -** массакүләм мәгълүмат чараларында ярышлар процессын һәм нәтиҗәләрен яктырта.

**5. Ярышлар үткәрү программасы һәм тәртибе.**

***Ярышлар Олимпия системасы буенча уздырыла***.

Спорт залларында узучы барлык ярышлар 9:00 сәгатьтә башлана, тышта уздырылучы ярышлар үткәрү вакыты оештыру комитеты тарафыннан (һава шартларына бәйле рәвештә) килештерелә.

**СПАРТАКИАДАНЫ АЧУ**

**Үткәрү срогы:** 01 февраль, 2020 ел.

**Үткәрү урыны:** «Спорт мәктәбе» МБУ спорт залы (Универсаль спорт залы)

**ВОЛЕЙБОЛ һәм БАДМИНТОН**

**Үткәрү вакытлары:**

**2020 елның 01 февралендә** волейбол буенча хатын-кызлар командалары, бадминтон буенча ирләр (бадминтон буенча 2 ир-аттан торган команда составы) уйный.

**2020 елның 02 февралендә** волейбол буенча ир-ат командалары, бадминтон буенча хатын-кызлар (бадминтон буенча 2 хатын-кыздан торган команда составы) уйный.

**Үткәрү урыны:** «Спорт мәктәбе» МБУ спорт залы (Универсаль спорт залы)

**ВОЛЕЙБОЛ**. Волейбол буенча ярышлар өч партиядән 25 очкога кадәр, 2 очко аерма белән үткәрелә. Ике партияне бер команда откан очракта, өченче партия үткәрелми. 3 партия уены кирәк булганда, 15 очкога кадәр дәвам итә, чик очко – 17. Җиңүче очколарның иң зур суммасы буенча билгеләнә: җиңү өчен – 2 очко, җиңелү өчен – 1 очко, килмәү өчен – 0 очко бирелә.

**БАДМИНТОН.** Бадминтон буенча ярыш 3 партиядән 11 очкога кадәр, 2 очко аерма белән үткәрелә. Беренче партияне команданың беренче ракеткасы уйный, икенче партияне – икенче ракетка. Ике партияне бер команда откан очракта, өченче партия үткәрелми. Отылган партияләр тигезлеге булган очракта, 3 партия парлы разрядта уйнатыла.

**МИЛЛИ КӨРӘШ, ШАХМАТ һәм ШАШКА**

**Үткәрү срогы:** 08 февраль, 2020 ел.
**Үткәрү урыны:** «Спорт мәктәбе» МБУ спорт залы (Универсаль спорт залы)

## МИЛЛИ КӨРӘШ

Ярыш 70 кг, 85 кг һәм 85кг. нан артык авырлык категорияләре буенча уздырыла. «Капма-каршы».

## ШАХМАТ һәм ШАШКА

(Шахматка 1 ир-ат һәм шашкага 1 хатын-кыз)

Ярышның формуласы катнашучы командалар санына карап билгеләнәчәк. Җиңүче җыелган очколарның иң зур суммасы буенча билгеләнә. Ике яки берничә команданың очколары тигез булган очракта, җиңүче FIDE кагыйдәләре буенча билгеләнә.

## БАСКЕТБОЛ

**Үткәрү срогы:** 09 февраль, 2020 ел.
**Үткәрү урыны: :** «Спорт мәктәбе» МБУ спорт залы (Универсаль спорт залы)

Команда составы: 5 уенчы + запас уенчылар. Ярышлар җирәбә салу буенча үткәрелә.

## БИАТЛОН һәм ӨСТӘЛ ТЕННИСЫ

**Үткәрү срогы:** 16 февраль, 2020 ел.
**Үткәрү урыны:** «Кояшлы Ык» яр буе (Чаңгы базасы), «Спорт мәктәбе» МБУ спорт залы (Универсаль спорт залы)

## БИАТЛОН

Катнаш эстафета (2 хатын-кыз + 2 ир-ат, 1 км. – хатын-кызлар, 1 км. – ир-атлар) – «Кояшлы Ык» яр буе. Биатлон эстафета узышының беренче катнашучылары, катнашучы командалар санына бәйле рәвештә, судья командасы буенча старт ала (бергә, яисә 30 секунд вакыт интервалы белән). Билгеле бер дистанция узганнан соң (450 метр), һәр спортчыга аягүрә басып, биш мишеньга ату кирәк булачак (мишень диаметры 10 см, ату дистанциясе 10 метр). Биатлончы тидерә алмаган очракта, ялгышлар саны буенча, штраф әйләнеше үтү белән җәзалана. Аннары тагын бер әйләнешне үтеп, спортчы эстафетаны киләсе катнашучыга тапшыра. Узыш барышында спортчыларга түгәрәкләрне кисүеп чыгу, штраф түгәрәкләренә игътибар итмәү, бер-берсенә аңлы физик йогынты ясау тыела. Биатлон кагыйдәләре катнашучыларга чит мишеньгә атуны тыя. Спортчының чит мишеньгә төгәл әләгүе тидермәү дип

санала. Ярышның җиңүчесе булып дистанциядә иң яхшы вакыт күрсәткән команда танылa. Пневматик винтовканы (бер разрядлы) команда үзе белән алып килә.

## ӨСТӘЛ ТЕННИСЫ

Өстәл теннисы буенча ярышлар өч партиядән 11 очкога кадәр, 2 очко аерма белән үткәрелә. Беренче партияне ир – ат, икенче партияне хатын-кыз уйный. Ике партияне бер команда откан очракта, өченче партия үткәрелми. Отылган партияләр тигез булган очракта, 3 партия парлы разрядта уйнатыла.

## МИНИ-ФУТБОЛ һәм КУЛ КӨРӘШЕ (АРМСПОРТ)

**Үткәрү срогы:** 22 февраль, 2020 ел.
**Үткәрү урыны:** «Спорт мәктәбе» МБУ спорт залы (Универсаль спорт залы)

### МИНИ-ФУТБОЛ.

Команда составы: 5 уенчы (4 уенчы, 1 капкачы) + запас уенчылар. Ярышлар җирәбә салу буенча үткәрелә. Тупны ыргытканда капкачы тупны мәйданның яртысыннан чыгарырга тиеш түгел. Әгәр капкачы тупны мәйданчыкның икенче яртысына ташласа, туп көндәш командасына күчә.

### КУЛ КӨРӘШЕ

«Капма-каршы»
- Ир-атлар 75 кг. кадәр, 90 кг. һәм 90 кг. артык авырлык категориясендә.
- Хатын-кызлар 60 кг. кадәр, 75 кг. һәм 75 кг. артык авырлык категориясендә.

## ЙӨЗҮ, АРКАН ТАРТУ

**Үткәрү срогы:** 23 февраль, 2020 ел.
**Үткәрү урыны:** «Мөслим гимназиясе» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе, «Спорт мәктәбе» МБУ спорт залы (Универсаль спорт залы).

### ЙӨЗҮ

**Үткәрү урыны:** «Мөслим гимназиясе»: Эстафета (2 ир-ат + 1 хатын-кыз; 3 х 50м) иректе стиль белән.

### АРКАН ТАРТУ

**Үткәрү урыны:** «Спорт мәктәбе» МБУ спорт залы (Универсаль спорт залы).

Команда составы - 5 кеше. Гомуми авырлыгы 450 кг. га кадәр булган командалар арасында очрашу өч омтылыштан тора. Командаларның берсе ике омтылышта җиңү яулаган очракта, өченчесе үткәрелми. Һәр омтылыштан соң командалар урыннар белән алышына һәм ял итә (ике минуттан да артык түгел). Бутсы яки шиплы башка аяк киеме рөхсәт ителми.

**СУПЕРФИНАЛ**

**Үткәрү урыны:** «Спорт мәктәбе» МБУ спорт залы (Универсаль спорт залы), ССК «Юность», «Мөслим гимназиясе»

**Үткәрү срогы:** 07 март, 2020 ел, 9:00 сәг.

**СУПЕРФИНАЛ**да оешмалар, предприятиеләр һәм авыл җирлекләре арасында гомумкоманда зачетында 1 һәм 2 урыннарны алган командалар катнашачак. Коллегия тарафыннан билгеләнгән барлык ярыш төрләре дә бер көнне була. Суперфиналда барлыгы 5 спорт төре узачак, аларның 3 төре мәҗбүри:

**Алар - волейбол (хатын-кызлар һәм ир-атлар), мини-футбол (ир-атлар), бадминтон (хатын-кызлар һәм ир-атлар). Ярышларның калган 2 төре, 2 мартта «Мизгел» яшьләр үзәгендә оешмалар, предприятиеләр һәм авыл җирлекләре арасында ике җиңүче команда вәкилләре һәм авыл җирлекләре Башлыклары катнашында, җирәбә салу буенча билгеләнә.**

**Әлеге Нигезләмә ярышларга рәсми чакыру булып тора!**

Белешмәләр өчен телефон: 2-59-48

**ГАРИЗА үрнәге**
**Мөслим муниципаль районы оешмалары һәм предприятиеләре арасында XXX кышкы спартакиадада катнашучы**
**_____________________________________________ командасы.**

**___________________________(спорт төре)**

Дата «___» ____________2020 ел. Мөслим

| № | Ф.И.О. (тулысынча) | Туган елы | Эш урыны | Табиб рөхсәте | Табиб имзасы |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | | | | | |

Кертелгән _________ кеше
Врач ____________

Команда вәкиле: ______________ /____________/

Учреждение начальнигы: ______________ /____________/

2.1 нче кушымта

**Оешма һәм предприятиеләр арасында XXX кышкы Спартакиада очколарын исәпләү таблицасы**

| Урын – очколар саны | Урын – очколар саны | Урын – очколар саны |
|---|---|---|
| **1 - 80** | **8-51** | **15-37** |
| 2-75 | **9-48** | **16 - 36** |
| **3-70** | 10-45 | **17-35** |
| **4-65** | **11 - 43** | **18-34** |
| **5-60** | **12-41** | **19 - 33** |
| 6-57 | 13-39 | **20-32** |
| **7-54** | **14-38** | **21 - 31** |